Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе **Р.З. Закировның чыгышы**

Хөрмәтле Президент!

Хөрмәтле коллегалар!

Уважаемые участники заседания!

Безнең бүгенге утырыш бик мөһим һәм актуаль проблемага багышланган. Әйе, җәмәгать оешмалары һәм хакимият структуралары мөнәсәбәтләре бүген илкүләм, хәтта дөньякүләм игътибар үзәгендә. Бу юкка гына шулай түгел, соңгы вакытта Русия Федерациясендә җәмәгать оешмаларына карый торган шактый күп яңа законнар кабул ителде. Һәм әйтергә кирәк, алар илебез җәмәгатьчелегендә шактый каршылыклы фикерләр дә тудырды, бүген әлеге законнар тирәсендә кызу гына бәхәсләр дә бара. Әмма яңа законнар нинди генә булмасын, ошыймы алар безгә, ошамыймы, без аларны үтәргә тиеш. Бөтендөнья татар конгрессы үзенең эшчәнлеген нәкъ шул принцип нигезендә кора һәм алып бара.

Сез беләсез, Бөтендөнья татар конгрессы 1992 елда Татарстан Президенты фәрманы белән гамәлгә куелды. Шул заманнан бирле татар конгрессы хакимият структуралары белән тыгыз элемтә һәм конструктив хезмәттәшлек корып эш алып барырга тырыша. Кабатлап әйтәм, бу безнең өчен төп эш принцибы.

Бүген Бөтендөнья татар конгрессына Русия Федерациясенең төрле төбәкләрдә һәм дөньяның төрле илләрендә эшләп килгән 388 оешма керә. Шуларның 128-е 30 дан артык чит илләрдә урнашкан. Без бу саннарны горурланып әйтә алабыз, чөнки алар милләтебезнең масштабын һәм Татарстан Республикасының илдә тоткан урынын яхшы билгели.

Безнең Русия төбәкләрендә һәм чит илләрдә урнашкан оешмаларыбыз, шөкер, җирле хакимиятләр белән бик уңышлы хезмәттәшлек итәләр. Татар оешмалараы активистлары арасында җирле закон чыгару мәҗлесләрендә, муниципаль берәмлекләрдә депутат булып торучылары да байтак. Милләттәшләребез арасында уңышлы эшмәкәрләр дә җитәрлек. Әлбәттә инде, бизнес эшен хакимиятләр белән хезмәттәшлек иткәндә генә алып барып була, бу беркем өчен дә сер түгел. Шулай итеп, безнең горурланырга да нигебез бар: бик күп төбәкләрдә татарларның икътисади һәм мәдәни позицияләре шактый көчле.

Бу, әлбәттә, уңай күренеш, чөнки милләттәшләребезнең эшмәкәрлек өлкәсендәге уңышлары илдә татар факторын ныгыта һәм көчәйтә. Сез

беләсез, Татарстан Конституциясендә бик мөһим 14 нче матдә бар. Ул матдәдә Татарстан Республикасының бөтен татар халкының теле һәм мәдәнияты өчен җаваплы булуы турында әйтелә. Бүген Татарстан республикасының илдәге һәм чит илләрдәге татарлар белән элемтәләре ныгыган бер вакытта, мондый мөнәсәбәтләрнең кануни нигезе булуы бик зур әһәмияткә ия. Миңа, Бөтендөнья татар конгрессы җитәкчесе буларак, Татарстан Президенты Рөстәм Миннихановның төрле төбәкләрдәге татар җәмәгатьчелеге белән очрашуларында катнашырга туры килә. Алар искиткеч күтәренке рухта уза һәм һичшиксез ике як өчен дә бик файдалы. Татарстан Республикасының Русия төбәкләре белән элемтәләрен ныгыту эшендә татар факторы бик мөһим роль уйный. Татарстанның төбәкләр белән ике яклы килешүләрендә татар телен һәм милли мәдәниятне саклау һәм үстерү турында да гел әйтелеп килә. Ә бу, милләттәшләребезгә үз мәнфәгатьләрен яклау өчен хокукый нигез бирә.

Бөтендөнья татар конгрессы күпкырлы эшчәнлек алып бара һәм безнең эшләрнең нигезен төрле хакимият структуралары белән хезмәттәшлек тәшкил итә. Әле күптән түгел Конгрессның V съезды узды, анда Русия төбәкләреннән һәм дөньяның төрле илләреннән меңнән артык делегат катнашты. Без Татарстан җитәкчелегенә бик рәхмәтле, чөнки аларның ярдәменнән башка мондый халыкара масштабтагы зур чараны уздырып булмас иде.

Бөтендөнья татар конгрессы, милләтебезнең киләчәген кайгыртып, татар яшьләре белән киң колачлы эш җәелдерде. Һәр ике ел саен без Бөтендөнья татар яшьләре форумнарын уздырабыз. Алар бик күп санлы татар яшьләре катнашында гаять күтәренке рухта узалар. Бу эштә без һәрдаим Татарстан яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министырлыгы ярдәмен тоеп торабыз. Алар белән хезмәттәшлек бик уңай нәтиҗәләр бирә. Киләсе елда Казанда яшь Русия ватандашларының Бөтендөнья форумы узачак. Бу зур чараны уздыру тәкъдиме белән Русия тышкы эшләр министрлыгы чыккан иде. Әлбәттә бу эштә Татарстанның соңгы елларда тупланган зур тәҗрибәсе нигез булып тора.

Безнең тагын бер масштаблы проект – ул илнең татар авыллары белән элемтәләр урнаштыру. Уйлап карагыз, Бөтендөнья татар конгрессы Русия Федерациясенең төбәкләрендә урнашкан 4300 татар авылы турында мәгълүмат туплады. Бу да илдәге татар факторының әһәмиятен яхшы тасвирлый. Шунысын да әйтергә кирәк, татар авыллары арасында бөтен илгә үрнәк булырлык төрле яктан шактый уңышлылары җитәрлек.

Аларның уңышлары нигезендә милләтебезгә хас булган күркәм сыйфатлар ята: эш сөючәнлек, тырышлык, тапкырлык, иман, җаваплылык һәм башкалар. Уңышлы татар авылында, гадәттә, дин көчле, мәчетләр гөрләп эшләп тора.

Иң мөһиме – уңышлы татар авыллары үзләренең икътисади нигезләрен, эшмәкәрлекне киң җәелдерү аркасында булдырганнар. Шуны истә тотып Бөтендөнья татар конгрессы Авыл эшмәкәрлеген үстерү проектын башлап җибәрде. Быел без авыл эшмәкәрләренең II Бөтенрусия җыенын уздырдык. Минемчә, бу бик мөһим эш, чөнки татар авылларын саклыйбыз дисәк, беренче чиратта аларның икътисади нигезен булдырырга һәм ныгытырга кирәк. Шушы Авыл эшмәкәрлеген үстерү проектын без Татарстан авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министырлыгы белән бергәлектә алып барабыз. Шунысын да әйтергә кирәк, бу эшләр Татарстан Президенты Рөстәм Миннихановның фатихасы белән башланып китте.

Бөтендөнья татар конгрессы, авыл эшмәкәрлегенең әһәмиятен танып, бу өлкәдә башка төрле эшләр дә алып бара. Бүген илдә хәләл ризык базары яралып килә, мондый ризыкка ихтыяҗ артканнан – арта бара. Шуны истә тотып, БТК башкарма комитеты Хәләл ризык җитештерү регламентын әзерләде. Безнең максат-хәләл ризыкның илкүләм стандартын булдыру. Чөнки ансыз булмый. Вакыт, вакыт бу өлкәдә төрле хәрәмләшү-алдашу очраклары да ачыкланып тора. Шуңа да без Казанда яңа ачылган “Агропромпарк” базарында Хәләл ризык сегментын булдыру тәкъдиме белән чыккан идек. Кызганыч, әлегә бу мәсьәлә хәл ителмәгән.

Соңгы елларда Русия төбәкләрендә һәм чит илләрдә яшәүче татар яшьләрен Татарстан югары уку йортларына җәлеп итү программасы да масштаблы проектка әверелде. Бу эшне Бөтендөнья татар конгрессы Татастан мәгариф һәм фән министырлыгы белән тыгыз хезмәттәшлектә алып бара. Шушы программа кысаларында ел саен йөзләгән яшь милләттәшләребез Татарстанга килеп, республика югары уку йортларына укырга керәләр. Монда минем Кытай халык республикасыннан килеп укучы татар яшьләре турында аерым әйтәсем килә. Минемчә, бу безнең халыкара күләмдә бик кирәкле эш булып чыкты. Әлбәттә, бу эштә федераль хакимиятләр белән хезмәттәшлек булмаса, аны тормышка ашыру гомумән мөмкин булмас иде. Безгә Русия тышкы эшләр министырлыгы читтәге милләттәшләр белән элемтә тотуда, алар белән хезмәттәшлек итүдә бик нык ярдәм итә.

Татарстан мәгариф министрлыгына яңа җитәкче килгәч, безнең әлеге дәүләт структурасы белән хезмәттәшлек бермә-бер артты. Милли мәгариф мәсьәләләре Бөтендөнья татар конгрессының һәрвакыт игътибар үзәгендә булды. Шуңа да без мәгариф министрлыгына бөтен республикабызга үрнәк булырлык татар гимназияләрен ачу проектын эшләү тәкъдиме белән чыктык. Якын елларда мондый проект тормышка ашыр дип өметләнәбез.

Бүген татар телен укыту проблемасы алдыбызга бөтен кискенлеге белән килеп басты. Шушы мәсьәләләрне хәл итү йөзеннән Бөтендөнья татар конгрессы Татарстан мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә ике тапкыр татар укытучыларының илкүләм съездларын уздырды. Шушыңа өстәп, Бөтендөнья татар галимнәре форумнарында әйтеп үтәргә кирәк. Былтыр аның икенчесе узды, һәм анда татар милләтенең зур интеллектуаль потенциалга ия булуы ачык күренде.

Бөтендөнья татар конгрессы үзенең беренче көннәреннән башлап Татарстан мәдәният министырлыгы белән тыгыз хезмәттәшлек алып бара. Заманында Татарстаннан читтә урнашкан төбәкләрдә халкыбызның милли бәйрәме - Сабантуйларны яңадан торгызу гамәле безнең зур күләмле уртак эшебез булды. Әйтергә кирәк әлеге гамәл халкыбызда киң яклау тапты, бүген без дөньякүләм Сабантуй этно-мәдәни хәрәкәте барлыкка килде дип әйтә алабыз. Уйлап карагыз, бүген Сабан туйлары Русиянең 70 ләп төбәгендә, дөньяның 30 га якын илендә үтә. Әлеге милли бәйрәм чараларында дистәләгән мең төрле милләт кешеләре катнаша. Бу, һичшиксез, Русия Федерациясе мәдәни тормышында татар факторының көчәюен тасвирлый. Шуны да әйтергә кирәк, 2013 елда Төмәндә федераль Сабантуй, Пермь өлкәсендә Бөтенрусия авыл Сабантуе, ә Санкт-Петербург каласында 1 нче Халыкара Сабантуй бәйрәмнәре узачак. Бу мәгълүматлар Сабантуй этно-мәдәни хәрәкәтенең масштабларын бик ачык күрсәтә.

Бөтендөнья татар конгрессы Татарстан мәдәният министырлыгы белән бергәлектә халыкара күләмдә “Татар моңы” җыр фестивальләре проектын да тормышка ашырып килә. Әлеге фестиваль бик күп яшь талантларга олы сәхнәгә юл ачты. Шулай ук төрле төбәкләрдә Бөтенрусия “Түгәрәк уен” татар фольклоры фестивальләре уздырыла. Һәр тобәктә “Татар кызы” һәм “Татар егете” дип аталган бәйгеләр, “Урал сандугачы”, “Иртыш моңнары”, “Себер йолдызлары”. Бу этно-мәдәни бәйгеләрдә илебезнең дистәләгән төбәкләреннән кызлар һәм егетләр катнаша.

Озак еллар Бөтендөнья татар конгрессы Татарстан сәнәгать һәм сәүдә министырлыгы белән хезмәттәшлек алып барды. Русия төбәкләрендә

уңышлы эшләп килгән татар эшмәкәрләре безнең министырлык белән уртак оештырыла торган “Татарстанның эшлекле хезмәттәшләре” дигән форумда бик теләп катнашып килделәр. Шушы хезмәттәшлекнең нәтиҗәсе буларак, илнең күп кенә төбәкләрендә “Татарстан” сәүдә йортлары ачылды һәм уңышлы гына эшләп китте. Кызганыч, бүген бу бик кирәкле эшләр күзгә күренеп сүлпәнәйде. Шул сәбәпле төбәкләрдәге үз вакытында Татарстан белән шактый уңышлы хезмәттәшлек алып барган эшмәкәрләрнең моң-зарын ишетергә туры килә. Ә бит нәкъ шушы кешеләр үз төбәкләрендә Татарстанның икътисади йогынтысын уздыруга күп көч куйганнар иде. Безнең мондый позицияләрне югалтырга һич хакыбыз юк.

Бүген Бөтендөнья татар конгрессының күпкырлы эшчәнлеге төрле дәрәҗәдәге хакимиятләр белән даими хезмәттәшлеккә нигезләнгән. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, мондый эшчәнлек алып барыр өчен конгресска бөтен шартлар тудырылган. Әлбәттә, буз шушындый эшлекле мөнәсәбәтләр урнашудан бик канәгать һәм республика җитәкчелегенә бик рәхмәтле. Күреп торабыз, бүген дөньяда да, илдә дә, милләтара, динара мөнәсәбәтләр шактый катлаулы. Шуңа да алар һәрвакыт киң җәмәгатьчелекнең дә, хакимиятләрнең дә игътибар үзәгендә. Әгәр бүген Татарстанда әлеге мәсьәләләрдә тотрыклылык бар икән, бу бит күктән төшмәгән. Бу республика җитәкчелегенең дә, Татарстан халкының да уртак тырышлыгы нәтиҗәсе. Әгәр Бөтендөнья татар конгрессы татар телен, милли мәгарифне, милли мәдәниятне саклау эшен эзлекле рәвештә алып бара икән, без шундый ук гамәлләрне башка халыкларга да телибез. Илебез халыкларының бердәмлеген шушы юлда гына саклап була.

Игътибарыгыз өчен рәхмәт.